СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 10-17 от « 09 » ноября 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 24 январендәге «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләрен алуга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибе турында № 2-10 карарына үзгәрешләр кертү турында»

ТР Җир кодексының $32^1$ статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирүне оештыру максатында Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 24 январендәге «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләрен алуга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибе турында» № 2-10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләрен алуга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибенә (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 23 июлендәге 11-14 номерлы карары редакциясендә) (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә даими яшәүче гражданнар, әгәр алар җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торсалар, күпбалалы гаиләгә, өч һәм аннан да күбрәк бала, шул исәптән үги балалары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән, йә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла) күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлеген түләүсез бирү турында гариза биргән көнгә унсигез яше тулмаган булса;»

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында даими яшәү турындагы таләпкә туры килү (туры килмәү) Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының бишенче абзацы нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.»;

1.2. 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Исемлекләргә кертү турында карар кабул итү өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 10 пунктында каралган сроктан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Җир кодексының шул ук статьясы нигезендә билгеләнә торган документлар тапшыра. Татарстан Республикасы Җир кодексының күрсәтелгән статьясындагы күрсәтелгән пунктында каралган очракларда вәкаләтле орган документларны мөстәкыйль соратып ала.»;.

1.3.15 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «,Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 10 пунктында каралган очракларда кирәкле запрослар әзерләүне һәм аларны тиешле органнарга (учреждениеләргә) җибәрүне тәэмин итә;

1.4. 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 10 пунктында каралган документлар тапшырмаган очракта йә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган яисә вәкаләтле орган тарафыннан кабул итеп алынган документлар мөрәҗәгать итүченең индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен җир кишәрлеге алуга хокукын расламый икән, вәкаләтле орган исемлекләргә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Исемлекләргә кертүдән баш тарту турында гражданнарга хәбәр итү Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 12 пунктының икенче абзацы нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов